**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 28 декабрь № 992

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икъти-садый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республи-касының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 28 декабрь, 1078 нче, 2014 ел, 22 февраль, 109 нчы, 2014 ел, 24 февраль, 118 нче, 2014 ел, 30 апрель, 284 нче, 2014 ел, 2 июнь, 374 нче, 2014 ел, 17 июнь, 418 нче, 2014 ел, 8 июль, 473 нче, 2014 ел, 9 июль, 477 нче, 2014 ел, 25 август, 612 нче, 2014 ел, 1 октябрь, 709 нчы, 2014 ел, 24 ноябрь, 901 нче, 2014 ел, 6 декабрь, 956 нчы, 2014 ел, 31 декабрь, 1083 нче, 2015 ел, 1 июнь, 390 нчы, 2015 ел, 24 июнь, 459 нчы, 2015 ел, 25 июнь, 460 нчы, 2015 ел, 28 июль, 549 нчы, 2015 ел, 16 октябрь, 770 нче һәм 2015 ел, 30 ноябрь, 906 нчы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортында «Программаның дәүләт заказчылары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Программаның дәүләт заказчылары | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы<br>Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы |

| | |
|---|---|
| | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы<br>Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты<br>Татарстан Республикасының Социаль-икътисади мониторинг буенча дәүләт комитеты<br>Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты<br>Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы<br>Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе»; |

Программаның «2014-2020 елларга Татарстан Республикасында дәүләт икътисади сәясәтен камилләштерү» ярдәмче программасының I бүлегендә:

«Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль заказлар белән идарә итү системасын камилләштерү» бүлекчәсендә:

беренче абзацта «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар китерүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру турында» 2005 елның 21 июлендәге 94-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен «дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу тармагында контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «гамәлгә ашыра» сүзләрен «гамәлгә ашырды» сүзләренә алмаштырырга;

«Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнарын һәм җирле үзидарә органнарын үз вазыйфаларын тормышка ашырганда мәгълүмати тәэмин итү һәм булышлык күрсәтү» бүлекчәсенең унберенче абзацында «үткәрелә» сүзләрен «үткәрелде» сүзләренә алмаштырырга;

Программага «2015 – 2018 елларга Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерын үстерү» ярдәмче программасында (алга таба – Ярдәмче программа):

Ярдәмче программа паспортында «Ярдәмче программаның дәүләт заказчылары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программаның дәүләт заказчылары | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы<br>Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы<br>Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе»; |

Ярдәмче программаның I бүлегендәге «Кластер катнашучылары (Ярдәмче программа катнашучылары)» бүлекчәсендә:

3 пунктта:

«Интерскол Алабуга» ЯАҖ» сүзләрен «Интерскол-Алабуга» АҖ» сүзләренә алмаштырырга;

«, «Протон» ЯАЖ, «Лин Вектор» ҖЧҖ, «РариТЭК» ҖЧҖ, «Компитенция һәм Инновация республика Интеграцияләнгән үзәге» ҖЧҖ, «Зәй нефть эшкәртү» ҖЧҖ сүзләрен өстәргә;

5 пунктка «, «Химия технологияләре тармагында төбәк инжиниринг үзәге» АҖ, «Системалы үстерү институты» автоном коммерциячел булмаган оешма» сүзләрен өстәргә;

Ярдәмче программаның IV бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«IV. Ярдәмче программаны тормышка ашыру механизмнары

Федераль башкарма хакимият органнары, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары, Кластер катнашучыларының мәнфәгатьләрен саклау һәм аларның бәйләнеше Ярдәмче программа белән идарә итүне оештыруның төп принцибы булып тора.

Ярдәмче программаны тормышка ашыру белән идарә итүне Ярдәмче программаның яраштыручысы – дәүләт заказчысы - Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы гамәлгә ашыра.

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы Россия Федерациясе Икътисади үсеш министрлыгы һәм федераль башкарма хакимият органы – әлеге Ярдәмче программада каралган чараларны тормышка ашыруга федераль бюджеттан субсидия алуга заявка әзерләү өлешендә федераль бюджет акчасын төп бүлүче белән үзара багланышларны гамәлгә ашыру буенча вәкаләтле орган булып тора.

Дәүләт заказчысы-яраштыручы:

Ярдәмче программаның җаваплы ярдәмче үтәүчеләре белән багланышларны гамәлгә ашыра, чараларын тормышка ашыруны яраштыруны һәм тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра;

Ярдәмче программа чаралары исемлеген, Ярдәмче программаның максатчан индикаторларын һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләрен, чаралар буенча чыгымнарны һәм аларны үтәүчеләр составын әзерләүне һәм тәгаенләүне гамәлгә ашыра;

Ярдәмче программаны тормышка ашырганда барлыкка килә торган мәсьәләләрне анализлауны үткәрә;

чараларны тормышка ашыруның уңышлылыгын анализлауны үткәрә, аннары аларны кабатлауның һәм нәтиҗәләре тиражын билгеләүнең максатка ярашлы булуы турында карар кабул итә;

Ярдәмче программаның максатчан индикаторлары исемлеге буенча Ярдәмче программаны тормышка ашыру барышы турында статистик һәм аналитик мәгълүмат алып баруны оештыра һәм анализ үткәрә, шулай ук индикаторларның планлаштырылган мәгънәләре гамәлдәгеләреннән аерылып тору сәбәпләрен анализлый;

Ярдәмче программа күрсәткечләрен һәм судсидия бүлеп бирү белән бәйле чараларны үтәүне мониторинглау өлешендә Ярдәмче программаны тормышка ашыруны тикшерә.

Дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм Ярдәмче программаны тормышка ашыруда катнашучы оешмалар Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына түбәндәгеләрне тапшыра:

квартал саен, хисап аеннан соң килүче айның 15енә кадәр аның үтәлеше турында мәгълүматны;

ел саен, хисап елыннан соң килүче елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы раслаган форма буенча хисапны.

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы квартал саен, хисап чорыннан соң килүче айның 25енә кадәр билгеләнгән форма буенча Ярдәмче программаны тормышка ашыру барышы турында җыелма аналитик мәгълүмат әзерли.

Ярдәмче программа кысаларында субсидияләр алучы булып тора торган предприятиеләр-Кластер катнашучылары тарафыннан хисаплылык тапшыру составы һәм вакыты Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты расланган тәртиптә билгеләнә.»;

Ярдәмче программага 2 нче кушымтаның 26 пунктындагы 3 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы, Чаллы шәһәре IT-паркы (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\992.docx